ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.04.2021 ел Баулы шәһәре №58

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2021 елның икенче кварталына Баулы муниципаль районында гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 13 мартындагы «Бәяләп сату эшчәнлегенә бәйле социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) тәртибен раслау турында» 182 номерлы карары нигезендә (2020 елның 27 апрелендәге редакциясендә), Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның II кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2021 елның 26 февралендәге 94 номерлы боерыгы белән, 2021 елның II кварталына Баулы шәһәрендә һәм Баулы районында торак урынының бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыкның эксперт-консультация советы әзләнүләре нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен җ2021 елның икенче кварталына Баулы муниципаль районында гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын 27 682 (егерме җиде мең алты йөз сиксән ике) сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И.И. Хөснуллинга йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров